**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

# БОЕРЫК

02.06.2014 Казан ш. №11-55

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының 1 февраль, 2005 ел, №110 Указы белән расланган "Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен аттестацияләү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 19 март, 2014 ел, №156 Россия Федерациясе Президенты Указына һәм Россия Федерациясе Президентының 1 февраль, 2005 ел, №112 Указы белән расланган Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәгә туры китереп, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, №11-51боерыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 20.06.2011 ел, №11-60, 21.09.2011 ел, №11-83, 22.07.2013 ел, №17-69 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм аны

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә яки билгеләүдән баш тартуга нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итүгә хокуклы.";

3.2 пунктта "Министрлыкның "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында" дигән сүзләрне "Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләти мәгълүмат системасында" дигән сүзләргә алыштырырга;

3.3 пунктның "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"г) кирәкле һөнәри белемне, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт эшчәнлегенә (хезмәт итү) беренче тапкыр керешелгән очраклардан тыш) – нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган, яисә гражданинның хезмәт эшчәнлеген (хезмәт итү) раслаучы башка документлар;

белеме һәм квалификациясе турында, шулай ук, гражданинның теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча күтәрелүен яки квалификация бирелүен раслаучы документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре - нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган;";

3.3 пунктта:

"г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

түбәндәге эчтәлектәге "ж" – "к" пунктчаларын өстәргә:

"ж) мәҗбүри пенсия иминиятләштерүнең иминиятләштерү таныклыгы, хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш;

з) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында учетка кую турында таныклык;

и) хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен – хәрби учет документлары;

к) Россия Федерациясе законында күздә тотылган дәүләт сере булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар (кирәк булган очракта).";

3.4 пунктның беренче абзацында "аларны кабул итү турында игълан ителгән көннән соң" дигән сүзләрне " аларны кабул итү турында белдерүне Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырган көннән соң"дигән сүзләргә алыштырырга;

4.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс җиңүчесен гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм конкурс җиңүчесе белән хезмәт контракты төзелә.

Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән кандидатны Конкурс комиссиясе тарафыннан Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителгән очракта, әлеге затның ризалыгы белән, аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына (гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасының шул ук төркеменә) кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла.";

4.2. пунктта "Министрлыкның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында" дигән сүзләрне "Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләти мәгълүмат системасында" дигән сүзләргә алыштырырга.

6 пунктның "г" пунктчасы. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә №1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"г) кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаучы

документлар:

нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш), яки гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча вазыйфасында күтәрелүне яки квалификация бирелүне раслаучы документлар күчермәләре, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре;”.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**